**СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Мульма, ул. Центральная, 46а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мүлмә авылы, Үзәк ур., 46а

тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2 апрель 2021 ел** **№ 26**

## Советның 2019 елның 27 июнендәге 158 нче номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мүлмә авыл җирлеге Советының 2019 елның 27 июнендәге 158 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәнең (Советның 11.09.2020 № 216 карары редакциясендә) 3 бүлегенең 3.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле 17 пункт белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«17) алкогольле, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Зиннәтуллин